КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 декабрь г.Казань № 1214

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 ел, 11 август, 971 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләргә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне теркәү тәртибен һәм этләрнең потенциаль куркыныч токымнары исемлеген раслау турында» 2014 ел, 5 май, 298 нче карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 ел, 11 август, 971 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләргә, аларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар үз көченә керү датасына хуҗаларда булган өч айдан өлкәнрәк эт бер ел дәвамында мәҗбүри теркәлергә тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне хәбәрнамәчел (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 05 май, 298 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 11 август, 971 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 26 декабрь, 1214 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләр

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу өстәмә таләпләр «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 498-ФЗ номерлы Федераль закон) 13 статьясындагы 8 өлеше һәм «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы $1^1$ өлеше нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге өстәмә таләпләрдә кулланыла торган төп төшенчәләр 498-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган мәгънәләрдәге кебек кулланыла.

1.3. Әлеге өстәмә таләпләр түбәндәгеләргә кагылмый:

а) хезмәт урынында кулланыла торган хайваннарны асрауга һәм аларны файдалануга;

б) күрү буенча инвалидларны йөртүче этләрне йөрергә алып чыгуга.

## II. Йорт хайваннары хуҗаларының бурычлары һәм хокуклары

2.1. Йорт хайванының хуҗасы түбәндәгеләргә бурычлы:

а) этне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба - Ветеринария идарәсе) ведомствосындагы районнарның һәм шәһәрләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре булган оешмаларда (алга таба - Ветеринария учреждениеләре) ветеринария идарәсенең норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә теркәргә (алга таба - Тәртип);

б) йорт хайванының табигый, шул исәптән тулы рационлы азыкка, суга, йокыга, физик авырлыкка ихтыяҗын исәпкә алып, аны карауны гамәлгә ашырырга;

в) йорт хайванына шәһәр һәм шәһәр яны мохитендә гражданнар, техник чаралар, башка хайваннар белән куркынычсыз аралашу күнекмәләре бирү, шулай ук аларда төрле тышкы ярсыткычларга – табигый күренешләргә, әйләнә-тирәгә һәм башка тормыш күренешләренә битараф, тыныч яки салмак кызыксына торган (курыкмый торган, агрессив булмаган) мөнәсәбәт тәрбияләү максаты белән аны үз вакытында социальләштерүне тәэмин итәргә;

г) эттә аның гамәлләре белән җитәкчелек итү мөмкинлеген бирә торган күнекмәләрне булдыру;

д) Ветеринария идарәсенә яисә Ветеринария учреждениесенә башка хайваннарны яисә кешеләрне тешләү очраклары турында хәбәр итәргә һәм Ветеринария учреждениесе белгечләре каравы өчен йорт хайванын бирергә;

е) хуҗа ике һәм аннан күбрәк көн рәттән йорт хайванын тиешенчә карауны тәэмин итә алмаган очракта, өченче затлар белән килешеп, йорт хайванын асрау буенча чаралар күрергә;

ж) йорт хайванын алга таба асрау мөмкинлеге булмаган очракта, йорт хайванына яңа хуҗа, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында йорт хайванын түләүле яисә түләүсез нигездә тапшыру турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән эзләү буенча чаралар күрергә.

2.2. Хуҗалар тарафыннан йорт хайваннарын асрау һәм йөртергә алып чыгу әлеге өстәмә таләпләргә карата кушымта нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрау һәм йөртергә алып чыгу буенча методик тәкъдимнамәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2.3. Йорт хайваннарын асраганда түбәндәгеләр тыела:

а) йорт хайванын имгәтә, яралый һәм үтерә торган җиһаз һәм башка җайланмалар кулланырга;

б) йорт хайванын өйрәткәндә имгәтә һәм (яки) җәрәхәтләнә торган гуманссыз ысуллар кулланырга.

2.4. Йорт хайванының хуҗасы түбәндәгеләргә хокуклы:

а) 498-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләр үтәлгәндә шәһәр һәм шәһәр яны мохитендә йорт хайванын даими рәвештә куркынычсыз йөртергә алып чыгарга;

б) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Котыру авыруы чыганакларын таратуны һәм бетерүне булдырмауга юнәлдерелгән профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне билгеләү һәм гамәлдән чыгару буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 25 ноябрендәге 705 нче боерыгы белән расланган Котыру авыруы чыганакларын таратуны һәм бетерүне булдырмауга юнәлдерелгән профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне билгеләү һәм гамәлдән чыгару буенча ветеринария кагыйдәләренең 8 пунктында каралган тәртиптә Ветеринария учреждениеләрендә котыру авыруына каршы бушлай вакцинация ясарга;

в) 498-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын һәм әлеге өстәмә таләпләрне үтәү кысаларында гражданнар ягыннан хөрмәт күрсәтергә;

г) 498-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләрне һәм Россия Федерациясенең хокукый актлары белән расланган тиешле транспорт төрләрендә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен үтәгәндә җәмәгать транспортында йорт хайваннары белән йөрергә;

д) оешмаларда булуның эчке кагыйдәләре нигезендә йорт хайваннары белән аларда булырга;

е) 498-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләрне һәм әлеге өстәмә таләпләрне үтәгәндә гомуми

файдаланудагы территорияләр буйлап, махсус саклана торган табигать территорияләреннән башка, йорт хайваннары белән йөрергә;

ж) шәһәр мохитендә һәм шәһәр яны территорияләрендә, үткәрү урыннары милекчеләре белән килештереп, йорт хайваннары белән укулар һәм спорт дәресләре, күрсәтү һәм аң-белем тарату чаралары үткәрергә, гаилә белән ял итәргә.

## III. Йорт хайваннарын асрау

3.1. Йорт хайваннарын асраганда түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

а) этләр, токымына бәйсез рәвештә, ветеринария учреждениеләрендә аларның хуҗалары тарафыннан аларның туганнан соң өч айдан артмаган срокта Тәртп нигезендә мәҗбүри теркәлергә тиеш.

Яңа сатып алынган өч айлык һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге этләр сатып алынган көннән алып 30 календарь көн эчендә мәҗбүри теркәлергә тиеш.

30 календарь көннән артык булмаган срокта Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасы белән вакытлыча булган этләр теркәлергә тиеш түгел;

б) йорт хайваннарын асрау урыннары йорт хайваннарының индивидуаль, шул исәптән пространствога, температурага, яктыртуга һәм җилләтүгә ихтыяҗларын исәпкә алып, җиһазланган булырга тиеш;

в) эт хуҗасына милек хокукында яки башка законлы нигездә караган территориядә этләрне асрау түбәндәгечә рөхсәт ителә:

этнең үзе генә территориядән читкә чыгып китүен булдырмый торган территория коймасы булганда бәйдә тотып;

этнең үзе генә территориядән читкә чыгып китүен булдырмый торган территория коймасы булганда  бәйдә тотмыйча;

этнең үзе генә читкә чыгып китүен булдырмый торган вольерда тотып;

г) йорт хайваннарын ашату, хайванның токымына, авырлыгына, яшенә һәм торышына карап, даими рәвештә гамәлгә ашырыла. Азык белән йорт хайваны организмының кирәкле ихтыяҗлары тәэмин ителергә тиеш;

д) йорт хайваны эчә торган чиста су запасы йорт хайваннары эчә торган суның кимендә тәүлек нормасы күләмендә тәэмин ителергә тиеш. Йорт хайваннарының су эчү мөмкинлеге тәүлек буе булырга тиеш;

е) коммуналь фатирның торак урыннарында яки берничә гаилә били торган торак урында йорт хайванын асрау торак урыннар милекчесенең (милекчеләренең) ирекле  рәвештә төзелгән язма ризалыгы булганда гамәлгә ашырыла;

ж) арендалана торган торак урыннарда йорт хайванын асрау торак урын милекчесенең ирекле язма рәвештә төзелгән ризалыгы булганда гамәлгә ашырыла;

з) күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы урыннарында һәм аларның йорт яны территорияләрендә йорт хайваннарын асрау рөхсәт ителми;

и) күпфатирлы һәм индивидуаль торак йортларда йорт хайваннарын асраганда, шул исәптән урамда асраганда аларның хуҗалары, шулай ук аларны алмаштыручы затлар төнлә эш көннәрендә 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр, ә ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган авазлар белән озата барылган йорт хайваннарының гамәлләрен булдырмау буенча чаралар күрергә тиеш.

3.2. Татарстан Республикасы территориясендә әлеге өстәмә таләпләрнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган этләрне теркәү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

этләрне аларның тәненә уникаль цифрлы яисә хәрефле-цифрлы идентификация номерын (алга таба - чип) үз эченә алган маркирлаштыруның электрон чарасын кертү юлы белән маркирлау;

эт һәм аның хуҗасы турында ветеринария учреждениеләре тарафыннан Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба - Мәгълүмат системасы) кертү.

3.3. Эт һәм аның хуҗасы турында Ветеринария учреждениеләре тарафыннан мәгълүмат системасы түләүсез гамәлгә ашырыла.

Чип алу һәм аны этнең тәненә кертү эт хуҗасы хисабына тормышка ашырыла.

3.4. Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктларын оештыру, шулай ук зоокунакханәләрдә йорт хайваннарын асрау Россия Федерациясе илкүләм стандартында билгеләнгән «Продуктив булмаган хайваннар өчен хезмәт күрсәтүләр. Продуктив булмаган хайваннарны вакытлыча тоту буенча хезмәт күрсәтүләр. Гомуми таләпләр» дигән Р 57014-2016 нчы ГОСТ таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

## IV. Йорт хайваннарын йөрергә алып чыгу һәм алар белән башка урыннарга бару

4.1. Йорт хайваннарын йөрергә алып чыкканда һәм алар белән башка урыннарга барганда түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

а) йорт хайваннарын асрала торган урыныннан читкә алып чыкканда аларга муенчак һәм (яки) киң муенчак һәм муенчаклы бау кидерелергә яки аларның контрольдә тотылмый торган хәрәкәтләрен булдырмый торган башка җайланма кидерелергә тиеш (алар махсус букчада (контейнерда) яки йөрергә алып чыгучының кулында булган очраклардан тыш);

б) хуҗа белән эт гомуми файдаланудагы территориядә булганда, этнең муенчаклы бавы аның хәрәкәтен контрольдә тотарга, чит затларга һәм хайваннарга якын килүне булдырмаска, әйләнә-тирәдәгеләрнең иминлеген һәм уңайлыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган озынлыкта булырга тиеш;

в) гражданнар күпләп җыела торган урыннарда (50 дән артык граждан), эт хуҗасы чит затларның эткә якынаюын алдан әйтә һәм контрольдә тота алмаган хәлләрдә булганда, хуҗа кыска муенчаклы бау (метр ярымга кадәр) кулланырга һәм эткә аның индивидуаль үзенчәлекләреннән чыгып сайлап алынган борынчык кидерергә тиеш (эт күчереп йөртелә торган контейнерда булган очраклардан тыш), шулай ук этләр катнашында зоотехник, спорт һәм күңел ачу-агарту чаралары уздырганда;

г) эт белән җәмәгать транспортында йөргәндә, эт хуҗасы кыска муенчаклы бау (метр ярымга кадәр) кулланырга һәм эткә аның индивидуаль үзенчәлекләреннән чыгып сайлап алынган борынчык кидерергә тиеш (эт күчереп йөртелә торган контейнерда булган очраклардан тыш); Транспортта озак (20 минуттан артык) барылган яки температура югары (+20 °С тан артык) булган очракта, янәшәдәге граждан белән сөйләшеп килештерелгәннән соң, борынчыкны бераз бушайтырга яки җәмәгать транспортыннан төшкәнгә кадәр эттән салдырып торырга мөмкин (Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең «Потенциаль куркыныч этләр исемлеген раслау турында» 2019 елның 29 июлендәге 974 номерлы карары белән расланган потенциаль куркыныч этләр исемлегенә кертелгән этләрдән тыш);

д) 14 яшьтән кечерәк затлар белән йорт хайваннарын йөрергә алып чыгу зурлар белән генә рөхсәт ителә.

4.2. Түбәндәгеләр тыела:

а) этләрне үз-үзләрен тотышын контрольдә тота алмаган, шул исәптән алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган, хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган затлар тарафыннан урамда йөртү һәм гомуми файдаланудагы территорияләрдә күрсәтелгән затларның этләр белән булуы;

б) медицина, мәгариф һәм физкультура-спорт оешмалары территорияләрендә, гражданнар су керү өчен рөхсәт ителгән пляжларда һәм йорт хайваннары белән булырга законнар нигезендә тыелган башка территорияләрдә йорт хайваннары белән булу;

в) йорт хайванын хуҗасыз йөрергә алып чыгу.

Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга, шул исәптән аларны йөрергә алып чыгуга карата өстәмә таләпләргә кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрау һәм йөрергә алып чыгу буенча методик тәкъдимнамәләр

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу методик тәкъдимнамәләр Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрауга һәм йөрергә алып чыгуга карата җаваплы мөнәсәбәт культурасын үстерү максатыннан чыгып эшләнде, йорт хайваннары хуҗалары һәм аларны вакытлыча алмаштыручы затлар, зоояклау оешмалары волонтерлары, түләүсез яки түләүле нигездә йорт хайваннарын тотып тору хезмәтләре күрсәтүче затлар һәм Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын асрарга теләүче башка гражданнар өчен билгеләнде.

1.2. Әлеге методик тәкъдимнамәләр максатларында түбәндәге билгеләмәләр кулланыла:

зурлыгы буенча кечкенә эт – буе җилкә калкымыннан кимендә 30 сантиметр тәшкил итә торган эт;

зурлыгы буенча уртача эт – буе җилкә калкымыннан 30 – 45 сантиметр тәшкил итә торган эт;

зурлыгы буенча эре эт – буе җилкә калкымыннан 46 – 60 сантиметр тәшкил итә торган эт;

гигант эт – буе җилкә калкымыннан 60 сантиметрдан артыграк булган эт;

нәсел үрчетү – селекция принципларын үтәп һәм нәсел документациясен рәсмиләштереп, токым стандартлары нигезендә яхшы токымлы йорт хайваннарының файдалану һәм гәүдә торышы сыйфатларын саклап калу һәм яхшырту максаты белән аларны үрчетү;

нәселле йорт хайваны – токым стандартына туры килә торган һәм үрчетергә рөхсәте булган яхшы токымлы йорт хайваны;

ветеринария белгече – йорт хайваннарына ветеринария ярдәме күрсәтү белән шөгыльләнүче югары яки урта ветеринария белемле физик зат;

кинолог – төрле максатлар өчен өйрәтү (күнекмәләр бирү), үрчетү, күнегүләр ясау белән шөгыльләнүче белгеч;

эструс – имезүче ана хайваннарның парлашырга һәм аталанырга әзер булган җенси активлыгы чоры.

### II. Йорт хайваннарын асрау шартларына карата тәкъдимнәр

2.1. Татарстан Республикасы территориясендә торак урыннарда йорт хайваннарын асрау өчен минималь тәкъдим ителә торган мәйдан:

а) йортта асрала торган кечкенә этләр өчен – бер эткә кимендә 2,5 кв.метр торак мәйданы;

б) йортта асрала торган уртача һәм эре этләр өчен – бер эткә кимендә 3,5 кв.метр торак мәйданы;

в) йортта асрала торган гигант этләр өчен – бер эткә кимендә 5 кв.метр торак мәйданы;

г) йортта асрала торган мәчеләр өчен – бер мәчегә кимендә 3 кв.метр торак мәйданы;

д) вак йорт хайваннары (диңгез дуңгызлары, көзәннәр, кәрлә куяннар һ.б.) үзләренең төр үзенчәлекләренә туры килә торган читлекләрдә, террариумнарда һәм аквариумнарда асралырга тиеш.

2.2. Торак бүлмәдә йорт хайваннарын асрау өчен оптималь һава температурасы:

а) йортта асрала торган этләр өчен – +16 градустан + 25 градуска кадәр диапазонда;

б) йортта асрала торган мәчеләр өчен – +18 градустан + 28 градуска кадәр диапазонда;

в) читлекләр, террариумнар яки аквариумнар тора торган урыннарда йорт хайванының һәр төре өчен уңайлы температура – + 15 градустан + 28 градуска кадәр диапазонда булырга, бүлмәдә үтәли йөри торган җилләр булмаска тиеш.

2.3. Йорт хайванын эссе көнне кояш астында, ачык һавада яки температура түбән булганда җылытылмый торган урыннарда, начар җилләтелә торган урыннарда, шулай ук табигый яктылык төшми торган урыннарда (балконнарда, чоланнарда, подвалларда, чормаларда, гаражларда һәм башка урыннарда) асрарга һәм озак вакыт (сәгатьтән артык) тотарга тәкъдим ителми.

2.4. Ике якка ачылмалы тәрәзәләргә йорт хайванын имгәтми торган яки качып чыгып китүен булдырмый торган система белән җиһазландырырга киңәш ителә.

2.5. Зурлыгы буенча уртача, эре һәм гигант этләрне урамда вольерда асраганда:

а) вольерлар этләрнең иминлеген, уңайлыгын һәм сакланышын исәпкә алып җиһазланган булырга тиеш, шулай ук:

качып чыгып китүгә каршы конструкция (эретеп ябыштырылган рәшәткә, нык металл ятьмә) нык булырга, аның дивар биеклеге кимендә 2 метр тәшкил итәргә тиеш;

этне җилдән һәм яңгырдан сакларга (вольерның ике яки өч дивары тоташ булырга) тиеш;

этнең зурлыгына туры килә, җыела һәм сүтелә торган өй кебек будкасы булырга тиеш;

этне йөртергә алып чыгу өчен аерым иркен урын булырга тиеш;

вольерның түбәсе йөртергә алып чыга торган урынның бер өлешен каплап торырга тиеш;

вольерның ишекләре эчкә ачылырга һәм вольер диварына тиеп торырга тиеш;

б) даими асраганда этләр өчен урам вольерларының зурлыгы:

уртача һәм эре токымлы этләр өчен кимендә 10 кв.метр;

гигант токымлы этләр өчен кимендә 15 кв.метр;

эре токымлы ике эттән торган көтү өчен кимендә 15 кв.метр;

в) урамда асрала торган этләр өчен өй кебек будка:

эктопаразитларга каршы сезонлы эшкәртү өчен сүтеп җыелырга тиеш;

вольерның барлык зурлыгыннан дүрттән бер өлешен генә биләргә тиеш;

этнең зурлыгына туры килергә тиеш, әмма кимендә:

зурлыгы буенча уртача этләр өчен – 60 × 80 × 60 сантиметр (шул ук эзлеклелектә биеклек, тирәнлек, киңлек);

зурлыгы буенча эре этләр өчен – 80 × 110 × 80 сантиметр (шул ук эзлеклелектә биеклек, тирәнлек, киңлек);

зурлыгы буенча гигант этләр өчен – 100 × 130 × 100 сантиметр (шул ук эзлеклелектә биеклек, тирәнлек, киңлек).

2.6. Зурлыгы буенча уртача, эре һәм гигант этләрне урамда чылбыр белән асраганда:

а) территория барлык периметр буйлап башка йорт хайваннары территориясенә эләгүгә комачаулый торган, шулай ук чылбырдагы этнең киртә астын чокып чыгуны һәм аның өстеннән сикереп чыгуны кисәтә торган ысул белән киртәләнергә тиеш;

б) территориядә этнең зурлыгына туры килә торган, сүтеп җыела торган өй кебек будка урнаштырылырга тиеш;

в) чылбырның озынлыгы теләсә нинди зурлыктагы эт өчен кимендә 4,5 метр булырга тиеш;

г) чылбыр звеноларының калынлыгы эт зурлыгына туры килергә тиеш;

д) эткә билгеле бер радиуста территория буенча (койма буйлап, йорт буйлап һ.б.) хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә торган трост белән асрарга тәкъдим ителә.

2.7. Йорт хайваннары асрала торган урыннарда йорт хайваннарының электр чыбыкларына якын килүе тыела.

2.8. Этнең җәмгыятьтә үзен адекват тотуын һәм анда күнекмәләр булдыру максаты белән, шулай ук хуҗа белән эт арасында контакт булдыру өчен Татарстан Республикасы территориясендә этне социальләштерү, этне өйрәтү дәресләренә һәм кинология спорты белән шөгыльләнү дәресләренә йөрү тәкъдим ителә һәм хуплана.

2.9. Йорт хайваннарында кирәкмәгән, деструктив һәм (яки) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч булган тотыш барлыкка килгән очракта, мондый тотышның сәбәпләрен ачыклау һәм алга таба коррекция ясау өчен ветеринария белгечләренә, кинологларга мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә.

## III. Йорт хайваннарының сәламәтлеген саклау

3.1. Йогышлы авыруларны профилактикалау һәм алар белән авыруның кискен артуын булдырмау максатларында йорт хайваннарына вакцинация ясарга һәм, аларның асрау шартларына һәм урамга чыгу ешлыгына карамастан, ел саен катнаш вакциналар белән ревакцинация үткәрергә кирәк.

3.2. Паразитар инвазияләрне профилактикалау һәм аларның таралуын булдырмау максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

а) эндопаразитларга, гельминтларга каршы эшкәртү. Эшкәртү препаратлары һәм аларның календарь планы ветеринария белгече тарафыннан, әмма елга кимендә бер тапкыр билгеләнергә тиеш;

б) эктопаразитларга каршы эшкәртү:

марттан алып ноябрьгә кадәр иксодида талпаннарына каршы;

йорт хайванын асрау шартларына карап, ел әйләнәсе башка эктопаразитларга каршы.

3.3. Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар санын киметү максатларында нәселсез йорт хайваннарын үрчетүне булдырмаска тәкъдим ителә.

3.4. Татарстан Республикасы территориясендә нәселсез йорт хайваннарының үрчүен булдырмау максатларында, әгәр печтерү йорт хайваннары тормышына куркыныч янамый торган һәм яшенә туры килгән очракта, аларны печтерү процедурасы тәкъдим ителә. Эструс чорында йорт хайванына үзенең асрау территориясеннән читтә ирекле рәвештә контрольсез хәрәкәтләнүенә рөхсәт итмәскә.

3.5. Йорт хайванының сәламәтлеген һәм активлыгын саклап калу максатларында ветеринария белгечендә даими профилактик тикшерүләр узу тәкъдим ителә.

## IV. Йорт хайваннарын йөрергә алып чыгу һәм алар белән йөрү буенча тәкъдимнамәләр

4.1. Этне йөрергә алып чыкканда аның хәрәкәтләнүгә, социаль аралашуга, тикшеренүләргә карата яшь үзенчәлекләре, токым һәм индивидуаль ихтыяҗлары исәпкә алынырга тиеш. Хуҗага, этнең төр ихтыяҗларыннан чыгып, урамда йөрү маршрутларын, башка йорт хайваннары белән уйнау вакытларын һәм башка шөгыльләрен планлаштырырга тәкъдим ителә:

а) йортта асрала торган зур (ике яшьтән зуррак) этләргә тәүлегенә кимендә ике тапкыр йөртергә алып чыгарга тәкъдим ителә;

б) урамда асрала торган зур (ике елдан артык) этләргә асрау урыныннан читтә тәүлегенә кимендә бер тапкыр йөртергә алып чыгарга тәкъдим ителә;

в) көчекләрне (алты айга кадәр) һәм өлкән яшьтәге (сигез яшьтән башлап) этләрне йөрергә алып чыгу режимын хайваннарның индивидуаль үзенчәлекләреннән чыгып билгеләргә кирәк.

4.2. Йорт хайванының физиологик үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм этнең өзлексез борынчык киеп йөрү, ә мәченең яки башка кечкенә йорт хайванының ябык контейнерда булу вакытын исәпкә алып, йорт хайваны белән урамда йөрүне һәм башка урыннарга баруны планлаштырырга тәкъдим ителә:

а) һәр этнең анатомик һәм үз-үзен тотышындагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, борынчыкны сайлап алырга тәкъдим ителә; дөрес сайланган борынчык эткә һәм әйләнә-тирәдәгеләргә куркынычсызлыкны тәэмин итәргә тиеш, шулай ук эткә ачык авыз белән иркенләп сулыш алырга мөмкинлек бирергә тиеш;

б) һава сугуны (артык нык кызуны), йөрәкнең эшен авырайтуны һәм сәламәтлеккә бәйле башка проблемалар булуны булдырмау өчен этне борынчык белән бер сәгатьтән артык, ә температура 25 °С тан югарырак булганда 20 минуттан артык йөртергә киңәш ителми;

в) урамда йөргән һәм транспортта барган вакытта, теш казнасын йомык хәлдә тота торган ветеринария борынчыкларын кулланырга рөхсәт ителми, чөнки алар терморегуляцияне бозуга һәм йөрәкнең кискен җиткелекле эшләмәвен арттыруга китерергә мөмкин;

г) контейнерны/күчереп йөртү җайланмасын сайлаганда хайванның физиологиясен һәм ихтыяҗларын исәпкә алырга кирәк. Әгәр хайван башын, аркасын,

тәпиләрен, койрыгын имгәтмичә баса алса, контейнер/күчереп йөртү җайланмасы дөрес сайланган була.

4.3. Йорт хайванын оператив идентификацияләү максатларында аны хуҗасын озатмыйча, югалтуларсыз яки урлап чыккан, шулай ук аны тизрәк кайтару максатларында, хуҗага йорт хайваны хуҗасының телефон номеры белән йорт хайваны жетоны амунициясенә беркетергә киңәш ителә.

## V. Хуҗаларның йорт хайваннары белән эш итү күнекмәләрен булдыру буенча тәкъдимнамәләр

5.1. Татарстан Республикасы территориясендә хуҗаның йорт хайваннары белән эш итү күнекмәләрен булдыру (хайван белән элемтәгә керү, аның тотышын контрольдә тоту, хайванны өйрәтү һәм аның белән күнекмәләр ясау) өчен түбәндәгеләр тәкъдим ителә һәм хуплана:

а) йорт хайваннарын социальләштерү буенча дәресләр – мөстәкыйль дә, шулай ук белгечләр җитәкчелегендә дә;

б) этләрне база һәм профиль буенча өйрәтү (гамәли, спорт, аучылык, күргәзмә һ.б.);

в) спортның кинология төрләре белән шөгыльләнү (өйрәтүнең гомуми курсы, эзләү-коткару хезмәте, җигүле спорт һ.б.);

г) гамәли кинология өлкәсендә эшчәнлек, шул исәптән волонтерлык эшчәнлеге (йөртүче этләрне, коткаручы этләрне, терапевт этләрне әзерләү);

д) аң-белем тарату, мәдәни, спорт характерындагы кинология чараларында, шул исәптән Физкультура укытучысы көне, Кинолог көне, Россия чемпионатлары һәм кинология дисциплиналары буенча Россия кинология федерациясе чемпионатлары һәм башка бөтенроссия ярышлары кысаларында катнашу;

е) зоояклау оешмалары волонтерларының хуҗасыз хайваннар санын арттыруны профилактикалауга һәм приютларда хайваннарга ярдәм күрсәтүне популярлаштыруга юнәлдерелгән тематик белем бирү, аң-белем тарату һәм мәдәни чаралар оештыру һәм уздыру юлы белән республика социаль тормышында катнашуы;

ж) үз торак пунктларының социаль тормышында һәм аның инфраструктурасын үстерүдә йорт хайваннары хуҗаларының актив катнашуы;

з) йорт хайваннары хуҗаларының үзлегеннән белем алуы.